ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙКОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21,e-mail:mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление**
№__569__

**Карар**
от « 12 »____11_____2018 г.

Архив эше өлкәсендә муниципаль
хезмәтләр күрсәтү буенча
административ регламентларны
раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210 – ФЗ санлы Федераль законын, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законын, “Татарстан республикасы муниципаль архивлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең бердәй административ регламентларын раслау турында” Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 08.06.2016 елгы № 050 – ОД боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 21.05.2018 55 –ОД санлы боерыгын гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Расларга (яңа редакциядә):

1.1. Муниципаль милеккә караган, муниципаль архивта саклანучы архив белешмәләрен архив өземтәләрен, архив документлары күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәте күрсәтү буенча административ регламент (1№ лы кушымта).

1.2. Муниципаль милеккә караган, муниципаль архивта саклანучы архив документларын Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының уку залында эшләү өчен файдаланучыга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты. (2 № лы кушымта).

1.3. Юридик затларга архивлар эшендә һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты. (3 № лы кушымта).

1.4. Муниципаль милкенә караган, муниципаль архивта саклануچы архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты. (4 № лы кушымта).

1.5. Муниципаль архивка саклау өчен ликвидацияләнүче оешмаларның шәхси составы буенча документлар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында. (5 № лы кушымта).

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының "Архив эше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча административ регламентларны раслау турында" 2014 ел, 10 июнь, 777 санлы карарын белән расланган 51,52,53,54,55 санлы кушымталарны гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р.Хуҗәҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов